# ГАЛӘМ

*9 сыйныф*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

***№ 21***

***14.02.22-19.02.22***

**15 февраль герой шагыйребезнен туган коне.**
Ул — татар халкының сөекле улы, шигырьләре белән фашизмга каршы аяусыз көрәш алып барган бөек шагыйрь.
Аңа 1956 елда Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ул шулай ук әсирлектә язган «Моабит дәфтәрләре» җыентыгы өчен Ленин премиясенә лаек була.

Муса Җәлил дигәндә без батырлык,каһарманлык,талантлылык,тугрылык, кебек сүзләр кулланабыз.Ул чыннан да, бу сүзләрнең һәммәсенә лаек шәхес.

Тоткынлыкта язган шигырьләре 2 дәфтәр булып туган илгә кайта. ”Моабит дәфтәрләре” дип йөртелә алар. Дәфтәрләрдәге шигырьләрдә ничек кенә булмасын, мескенләнү дә, төшенкелеккә бирелү дә, язмышка кул селтәү дә юк. Аларда җиңүгә ышаныч, туган илгә мәхәббәт, фашизмга нәфрәт хисләре чагыла.

Мәктәбебездә дә Муса Җәлилнен туган көненә багышланган чара үткәрелде.

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.




Катыйльгә

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,

Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,

Кирәк икән, үләм аягүрә,

Балта белән башым киссәң дә.

Меңен түгел, бары йөзен генә

Юк итәлдем синең сыңарның,

Һәм халкымнан, кайткач, шуның өчен

Мин тезләнеп,гафу сорармын.

## СПОРТ

20 нче февальдә “Дельфин” спорт комплексында 2012 -2013 елда туган укучылар арасында районкуләм бадминтон ярышлары булып узды. Безнең мәктәптән 3 нче сыйныф укучылары Мингалимова Зәринэ, Вафин Рамазан, Гилемзянов Әмир һэм Мухаметшин Риназлар катнашты. Бу ярышка Буа Шәһәреннән дә спортчылар килгән иде Малайлар арсында 2 нче урынннны Мухаметшин Риназ яулады. Калган укучылар да бик матур уен курсәттеләр. Әфәрин егетләр. Район ярышына судьялык итәргә 7 сыйныфтан Шарипва Зилә, Мустафина Миләүшү һәм Зиятдинов Инсафлар бардылар. Югары дәрәҗәдәге професиналлыклары очен аларга рәхмәтебезне җиткерәсе килә.



